Республика Татарстан
**СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ахмадиева, д.26, п. Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК СОВЕТЫ**

Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы,423368
Телефон: (85559) 31-0-97,60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

**РЕШЕНИЕ**
22.03.2024 ел

**КАРАР**
№179

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 14 февралендәге 71 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында «Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктына ярашлы, Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 14 февралендәге 71 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил поселогы Советының 25.11.2022 № 111, 22.02.2023 № 130, 05.04.2023 № 135, 07.08.2023 №151, 01.11.2023 №157, 27.12.2023 №170 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 9.4 пунктында. «сведение» сүзеннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 6.1 пунктның 8 пунктчасы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру;»;

1.3. 5.5 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 13 пункт белән тулыландырырга:

«13) яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә әлеге Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба - анкетада булган мәгълүматлар).».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе

Р.Ә.Кәримов